ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 154**

**КАРАР**

**“22” 02 2024 ел**

2024 елның I кварталына торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлык үткәргән Болгар шәһәрендә һәм Спас муниципаль районында торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренү нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның I кварталына Спас муниципаль районы территориясендә «2020-2025 елларга Спас муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча чаралар үткәрүгә социаль түләүләрне исәпләү өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясе 38 266 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

В. А. Осокин